ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Югары Ушма авылында урнашкан торак пунктта 2026 елда елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

23 ноябрь 2025 ел № 2

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23.1 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Югары Ушма авылында гражданнар җыены карар итте:

1. 2026 елда Балтач районы Кече Лызи авыл җирлегенең Югары Ушма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булганнарга 700 сум күләмендә үзара салым кертергә, үзара салым суммасының 50 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән: 1нче һәм 2 нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән, сәләтсез гражданнардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, өлкән яшьтәге ялгыз пенсионерлардан, үз – үзләренә хезмәт күрсәтә алмаган гражданнардан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче тулы булмаган куп балалы гаилә әгъзаларыннан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче ялгыз аналардан, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә ашыгыч яки контракт хезмәте узучы, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту,
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү,
- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы Л.М.Михайлова